| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

**2018 елның 15 октябре** **№23**

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2017 елның 26 октябрендәге 10 номерлы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым базасын билгеләү тәртибенең бердәй датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015елның 26 октябрендәге 10 номерлы «Куакбаш _авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасының беренче абзацында «фатир» сүзләреннән соң «фатирлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 3 пунктчасының беренче абзацында «торак йортлары» сүзләреннән соң «торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 3 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"составына бер генә торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: К.Маркс ур., 15; Сходнево-Чертанл авылы - Ирек ур., 5б йорт; Чути авылы - Тынычлык клубы бинасында, 8а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны 2017 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы муниципаль районы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Әхмәтҗанова